**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Баграж авыл җирлеге составына керүче Урта Баграж торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**17.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2022 елның 17 нче ноябрендә "Сез 2023 елда Баграж авыл жирлегенең Урта Баграж торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:
- урам яктырткычларын ремонтлауга;
-агачларның ботакларын кисүгә;
-торак пункт эчендә юллардагы чокыр-чакырларны ямауга.
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 105 кеше кертелән, 55 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 55 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең Урта Баграж торак пунктында гражданнар җыены үткәнен, Халык җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. 2023 елда Баграж авыл жирлегенең Урта Баграж торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- урам яктырткычларын ремонтлауга;
- агачларның ботакларын кисүгә;
- торак пункт эчендә юллардагы чокыр-чакырларны ямауга.» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гранданнар цыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» уранаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Баграж авыл җирлеге Уставның 69 п.5 статься) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Баграж авыл җирлеге башлыгы П.Н. Минеев